**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 19 октябрь № 779

г. Казань

Татарстан Республикасының мәгариф белән идарә итүче муниципаль органнары, муниципаль белем бирү оешмалары, мәгариф белән идарә итүче муниципаль органнарның методик хезмәтләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген анализлауны гамәлгә ашыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8, 89 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган мәгариф оешмалары бәйләнешләрен тәэмин итү һәм Татарстан Республикасында гомуми белем системасын камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының мәгариф белән идарә итүче муниципаль органнары, муниципаль белем бирү оешмалары, мәгариф белән идарә итүче муниципаль органнарның методик хезмәтләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген анализлауны гамәлгә ашыру тәртибе турында нигезләмәне расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\779.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 19 октябрь, 779 нчы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасының мәгариф белән идарә итүче муниципаль органнары, муниципаль белем бирү оешмалары, мәгариф белән идарә итүче муниципаль органнарның методик хезмәтләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген анализлауны гамәлгә ашыру тәртибе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасының мәгариф белән идарә итүче муниципаль органнары, муниципаль белем бирү оешмалары, мәгариф белән идарә итүче муниципаль органнарның методик хезмәтләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген анализлауны гамәлгә ашыру тәртибен регламентлаштыра (алга таба – Нәтиҗәлелекне анализлау).

2. Нәтиҗәлелекне анализлауның максаты булып Татарстан Республикасында гомуми белем бирү системасын камилләштерү тора.

3. Нәтиҗәлелекне анализлауның төп бурычлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасында белем бирү системасын мониторинглау нәтиҗәләрен, массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан мәгълүматны, Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарына, башкарма хакимият органнарына һәм җирле үзидарә органнарына күзәтчелек оешмаларыннан һәм бүтән оешмалардан һәм гражданнардан кергән мәгълүматны, Татарстан Республикасында белем бирү оешмалары рейтингын анализлауны гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасында гомуми белем бирү системасын камилләштерү турында Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына тәкъдимнәр әзерләү һәм аларны кертү.

4. Нәтиҗәлелекне анализлауны үткәрүнең мәҗбүрилеге, ачыклыгы, халыкчанлыгы төп принциплары булып тора.

## II. Нәтиҗәлелекне анализлауны үткәрү тәртибе

5. Нәтиҗәлелекне анализлау Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы төзегән комиссия (алга таба – Комиссия) тарафыннан үткәрелә.

Комиссия саны һәм шәхси составы, аның эш тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасының мәгариф белән идарә итүче муниципаль орган, муниципаль белем бирү оешмасы, мәгариф белән идарә итүче муниципаль органның методик хезмәте җитәкчесе (алга таба – җитәкче) эшчәнлеген канәгатьләнерлек яки канәгатьләнмәслек дип тану критерийлары Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

6. Нәтиҗәлелекне анализлау елына бер тапкыр гамәлгә ашырыла.

7. Нәтиҗәлелекне анализлау йомгаклары буенча кимчелекләр билгеле булган очракта, әлеге кимчелекләрне бетерүгә методик яктан ярдәм итү максатында җитәкче белән әңгәмә үткәрелә.

8. Әңгәмә йомгаклары буенча җитәкче әңгәмә үткәрелгәннән соң 10 көн эчендә эштәге кимчелекләрне бетерү буенча план төзергә һәм аны Комиссиягә тапшырырга хокуклы.

9. Комиссия кимчелекләрне бетерү буенча планны алганнан соң 10 көн эчендә аны карап тикшерә һәм кирәкле төзәтүләр кертә, раслый һәм үтәү өчен җитәкчегә тапшыра.

10. Нәтиҗәлелекне анализлау нәтиҗәләре буенча Комиссия Татарстан Республикасы муниципаль районы яки шәһәр округы башлыгы исеменә гомуми белем бирү системасын камилләштерү һәм җитәкче эшчәнлеген канәгатьләнерлек яки канәгатьләнмәслек дип тану турында тәкъдимнәр юллый.

11. Комиссия йомгаклары Комиссиянең рәисе, рәис урынбасары, тавыш бирүдә катнашкан әгъзалары имзалаган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

12. Комиссия йомгакларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

## III. Комиссия карарларын тормышка ашыру

13. Җитәкче эшчәнлеген берничә тапкыр канәгатьләнмәслек дип таныган очракта Комиссия Татарстан Республикасы муниципаль районы яки шәһәр округы башлыгына җитәкченең биләгән вазыйфасына туры килмәве турында мәсьәләне карап тикшерү хакында тәкъдимнәр белән хат юллый.

F:\KARAR\2015\779.docx